СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2015 елның «15» апреленнән** **№ 43-262**

**«Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-214 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»**

«Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы Указының 2 статьясы, «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-214 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү бурычы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданга (алга таба – гражданин) йөкләнә.

Хисап елының 31 декабренә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасын (алга таба

– вазыйфалар исемлеге) биләгән Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә (алга таба – муниципаль хезмәт) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү бурычы йөкләнә.»;

б) 3 пунктта «Вазыйфалар исемлегендә каралган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктның «в» пунктчасында:

«алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «әлеге алыш-бирешләр башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 пунктта:

«вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы» сүзләрен «муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы» сүзләренә алмаштырырга;

«2, 3 һәм 5 пунктлар нигезендә» сүзләрен «2 пунктының беренче абзацы, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктта:

беренче абзацта «җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 13 пункта :

«алыш-биреш башкарылган» сүзләрен «алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш эшләнгән) сүзләренә алмаштырырга;

«алыш-биреш суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә» сүзләрен «әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 15 пунктның икенче абзацында «вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләрен «биләүгә дәгъва кылган муниципаль хезмәт вазыйфасына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2014 елның «11» ноябреннән
37-214 номерлы карарына
1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның «___» апрелендәге
_______ номерлы карарындагы
үзгәрешләр белән

**«Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы граждannar тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән тәкъдим итү тәртибе билгеләнә:

«Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, алар алган керемнәр, милек хокукында булган мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр);

«Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз чыгымнары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр).

2. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү бурычы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданга (алга таба – гражданин) йөкләнә. Хисап елының 31 декабренә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасын (алга таба – вазыйфалар исемлеге) биләгән Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә (алга таба – муниципаль хезмәт) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү бурычы йөкләнә.

3. Вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләнгәндә Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча гражданнар тарафыннан

керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра.

4.Керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

5. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә граждан тапшыра:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан (сайланулы эш урыны буенча элекке керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә документлар бирү елына кадәрге календарь ел өчен, шулай ук милек хокукында булган мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (хисап датасына);

б) гражданның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук гражданның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче көненә (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

6. Муниципаль хезмәткәр ел саен тәкъдим итә:

а) барлык чыганаклардан (акчалата эчтәлекне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында булган мөлкәт һәм хисап чоры азагына кадәр милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр);

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында белешмәләр.

7. Вазыйфалар исемлегенә кертелмәгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче һәм Вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 2, 3 һәм 5 пунктлары нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра.

8. Әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 6 пунктларында каралган мәгълүматлар Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторына тапшырыла.

9. Граждан яисә муниципаль хезмәткәр алар тарафыннан җирле үзидарә органының (муниципаль орган) кадрлар хезмәтенә тапшырылган мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын ачыклаган очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга мөмкин.

10. Объектив сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәткәр хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган очракта, әлеге факт муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиядә каралырга тиеш.

11. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан һәм муниципаль хезмәткәр тапшырган белешмә дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Граждан һәм муниципаль хезмәткәрләргә әлеге Нигезләмә нигезендә бирелә торган белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса.

Әлеге белешмәләр җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенә һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларына, вазыйфага билгеләнү һәм муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасыннан азат итү вәкаләтләренә ия булган затларга, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш ясалган) акча чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайты законнарда билгеләнгән тәртиптә, ә бу мәгълүматлар булмаган очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында аларның запрослары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан тапшырыла.

14. Вазыйфаи бурычларына граждан һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр белән эш итү керә торган муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда аларны фаш итсә яисә кулланса Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

15. Граждан яисә әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләргә шушы Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә муниципаль хезмәт вазыйфасына тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

белешмәләр, муниципаль хезмәткәргә ел саен тапшырыла торган мәгълүмат һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән граждан яисә муниципаль хезмәткәр кадрлар хезмәтенә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторынатапшырган очракта, Исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән булса, бу белешмәләр аларның язма гаризалары буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.

16. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмаган яисә ялган тапшырылган очракта, граждан муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куела алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылыкның башка төрләренә дучар ителә.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз чыгымнары турында тулы яисә дөрес булмаган белешмәләр бирү яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру, мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булган очракта, биләгән вазыйфасыннан азат итүне китереп чыгаручы хокук бозу була, билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәттән азат ителә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2014 елның «11» ноябреннән
37-214 номерлы карарына
2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның «___» апрелендәге
______ номерлы карарындагы
**үзгәрешләр белән**

**Гражданнар үзләренә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырырга тиешле «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны билгәндә «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

1. Муниципаль хезмәтнең югары һәм төп төркемнәре чикләрендә Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфалары.
2. Муниципаль хезмәтнең алыштыру коррупция куркынычы һәм рәсми бурычларны үтәү белән бәйле башка вазыйфалары:
- хакимият вәкиленең яки оештыру-күрсәтмә яисә административ-хуҗалык функцияләрен даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләтләр нигезендә башкару;
- гражданнарга һәм оешмаларга муниципаль хезмәт күрсәтү;
- контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру;
- бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлү турында карарлар әзерләү һәм кабул итү, шулай ук чикләнгән ресурсны бүлү;
- муниципаль мөлкәт белән идарә итү;
- муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашыру яисә лицензияләр һәм рөхсәтләр бирү;
- матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.